КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 апрель г.Казань № 371

Махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын махсуслаштырылган торак урыннары наймы шартнамәсе буенча яллаучы булып торган ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кергән затларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган, 23 яшькә җиткән затларга авыр тормыш шартларын җиңүдә ярдәм күрсәтү кирәклеге турында таныклаучы хәлләрне ачыклау тәртибен раслау хакында

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын махсуслаштырылган торак урыннары наймы шартнамәсе буенча яллаучы булып торган ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кергән затларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган, 23 яшькә җиткән затларга авыр тормыш шартларын җиңүдә ярдәм күрсәтү

кирәклеге турында таныклаучы хәлләрне ачыклау тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына әлеге Тәртип нигезендә махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын махсуслаштырылган торак урыннары наймы шартнамәсе буенча яллаучы булып торган ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кергән затларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган, 23 яшькә җиткән затларга авыр тормыш шартларын җиңүдә ярдәм күрсәтү кирәклеге турында таныклаучы хәлләрне ачыклауда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына булышлык күрсәтергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин